КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 декабрь г.Казань № 1315

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары

белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021 ел, 11 февраль, 70 нче; 2021 ел, 24 май, 366 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1026 нчы; 2022 ел, 22 гыйнвар, 39 нчы, 2022 ел, 11 июль, 665 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

5 пунктның бишенче абзацында «30 календарь көн» сүзләрен «10 календарь көн» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин